ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ ҺӘМ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ

# БОЕРЫК

**02.02.2016** **Казан шәһәре** **№ 56**

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан чит ил дәүләтләре, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый оешмалар һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен алу тәртибе турында Нигезләмәне раслау турында

2004 елның 27 июлендә кабул ителгән «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында» 79-ФЗ номерлы Федераль законны, Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 10 октябрендә кул куелган «Россия Федерациясе аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәтенең аерым вазыйфаларын башкаручы затларның мактаулы һәм махсус исемнәр, чит ил дәүләтләре, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый оешмалар һәм башка оешмаларның бүләкләрен алу тәртибе турында Нигезләмәне раслау турында» 506 нчы номерлы Указын, Татарстан Республикасы Президенты 2016 елның 12 гыйнварендә кул куйган УП-5 номерлы «Татарстан Республикасы Президенты билгели һәм азат итә торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын башкаручы затлар тарафыннан чит ил дәүләтләре, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый оешмалар һәм башка оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен һәм башка аерымлык билгеләрен (орден һәм медальләр) алу тәртибе турында Нигезләмәне раслау турында» Указының 3нче пунктын үтәү йөзеннән

боерам:

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре (алга таба – Министрлыкның гражданлык хезмәткәрләре) тарафыннан чит ил дәүләтләре, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый оешмалар һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен алу тәртибе турындагы бирегә теркәлгән Нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә) расларга.
2. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча секторга (Тайшибаева Л.Н.) Министрлыктагы гражданлык хезмәткәрләрен Нигезләмә белән таныштырырга һәм Министрлыкның гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан чит ил дәүләтләре, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый оешмалар һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен алу турында документларны кабул итү һәм саклау эшне оештырырга.
3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне министр урынбасары А.М.Миңгуловка йөкләргә.

Министр В.А.Леонов

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре һәм спорт
министрлыгының
2016 елның 2 февралендә
кул куелган
56 номерлы боерыгы тарафыннан
расланган

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ ҺӘМ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫНЫҢ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ГРАЖДАНЛЫК ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ ТАРАФЫННАН ЧИТ ИЛ ДӘҮЛӘТЛӘРЕ, ХАЛЫКАРА ОЕШМАЛАР, СӘЯСИ ПАРТИЯЛӘР, БАШКА ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАЛАР ҺӘМ ДИНИ БЕРЛӘШМӘЛӘРНЕҢ МАКТАУЛЫ ҺӘМ МАХСУС ИСЕМНӘРЕН, БҮЛӘКЛӘРЕН АЛУ ТӘРТИБЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Әлеге Нигезләмә тарафыннан Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре (алга таба – Министрлыкның гражданлык хезмәткәрләре) тарафыннан, әгәр Министрлыкның гражданлык хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларына әлеге оешмалар һәм берләшмәләр белән хезмәттәшлек керә икән, чит ил дәүләтләре, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый оешмалар һәм дини берләшмәләрнең бүләкләрен, мактаулы һәм махсус исемнәрен (алга таба – исемнәр, бүләкләр) (фәнни исемнәрдән тыш) алу тәртибе билгеләнә.

2. Министрлыкның гражданлык хезмәткәре исем, бүләкләр алган чакта Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрының (алга таба – министр) рөхсәтен алырга тиеш.

3. Министрлыкның исем, бүләк алган яисә чит ил дәүләте, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый оешма, дини берләшмәдән аны алачагы турында белдерү алган гражданлык хезмәткәре өч эш көне эчендә дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча секторга чит ил дәүләте, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый оешма яисә башка оешманың мактаулы яисә махсус исемен, бүләген алырга рөхсәт итү турында әлеге Нигезләмәнең 1нче Кушымтасындагы форма буенча төзелгән үтенеч (алга таба – үтенеч) язып бирә.

Үтенечне карау вакыты үтенечне әлеге Нигезләмәнең 8 пункты буенча дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча секторда теркәгәннән соң 10 көн тәшкил итә.

4. Министрлыкның исем, бүләк алудан баш тарткан гражданлык хезмәткәре дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча секторга өч эш көне эчендә чит ил дәүләте, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый оешма яисә башка оешманың мактаулы яисә махсус исемен, бүләген алудан баш тарту турында әлеге Нигезләмәнең 2нче Кушымтасында бирелгән форма буенча төзелгән белдерү кәгазен (алга таба – белдерү кәгазе) тәкъдим итә.

5. Гаризаны карау нәтиҗәләре буенча министр карар кабул иткәнче министрлыкның исем, бүләк алган гражданлык хезмәткәре исем, бүләккә документларның төп нөсхәсен һәм аңа караган документларның төп нөсхәсен аларны алганнан соң өч көн эчендә җаваплы саклауга дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча секторга тапшыра. Бу вакытта әлеге Нигезләмәнең 3нче Кушымтасында тәкъдим ителгән форма буенча төзелгән алыш-биреш акты төзелә.

6. Министрлыкның гражданлык хезмәткәре хезмәт командировкасы вакытында исем, бүләк алган яисә аңардан баш тарткан очракта, гариза яисә белдерү кәгазе бирү вакыты Министрлыкның гражданлык хезмәткәренең хезмәт командировкасыннан кайткан көненнән санала башлый.

7. Әгәр гражданлык хезмәткәре аңа бәйле булмаган сәбәпләр аркасында гариза яисә белдерү кәгазе бирә, исем, бүләккә документларның, аларның документларының төп нөсхәләрен әлеге Нигезләмәнең 3,4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән вакытта тапшыра алмаса, әлеге сәбәп беткән көннең икенче көненнән дә соңга калмыйча гариза яисә белдерү кәгазе бирергә, исем, бүләккә документларның, аларның документларының төп нөсхәләрен тапшырырга тиеш.

8. Гариза яисә белдерү кәгазен теркәү дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча сектор тарафыннан бирелгән көнне әлеге Нигезләмәнең 4нче Кушымтасындагы форма буенча төзелгән теркәү журналында ясала. Теркәлгән гариза яисә белдерү кәгазен дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча сектор өч эш көне эчендә карау өчен министрга җибәрә.

9. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча сектор ике эш көне эчендә Министрлыкның гражданлык хезмәткәренә гаризаны карау нәтиҗәләре буенча министрлык кабул иткән карар турында хәбәр итә һәм, имза куйдырып, аңа министр резолюциясе белән дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча сектор раслаган гаризаның (белдерү кәгазе) күчермәсен тапшыра. Министр резолюциясе белән гаризаның (белдерү кәгазе) төп нөсхәсе гражданлык хезмәткәренең шәхси эшенә теркәлә.

10. Әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән гражданлык хезмәткәренең гаризасын министр канәгатьләндергән очракта дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча сектор 10 эш көне эчендә гражданлык хезмәткәренә исем документларын, бүләкне һәм аның документларының төп нөсхәсен тапшыра. Бу вакытта әлеге Нигезләмәнең 3нче Кушымтасы буенча алыш-биреш акты төзелә.

11. Әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән гражданлык хезмәткәренең гаризасын министр канәгатьләндерүдән баш тарткан очракта, дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча сектор 10 эш көне эчендә исемгә караган документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аның документларының төп нөсхәләрен тиешле чит ил дәүләте органына, халыкара оешмага, сәяси партиягә, башка иҗтимагый берләшмәгә, дини берләшмәгә җибәрә.

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре һәм спорт
министрлыгының
Татарстан Республикасы
дәүләт граждалык
хезмәткәрләре тарафыннан
чит ил дәүләтләре, халыкара
оешмалар, сәяси партияләр,
башка иҗтимагый оешмалар
һәм дини берләшмәләрнең
мактаулы һәм махсус
исемнәрен, бүләкләрен алу
тәртибе турындагы
Нигезләмәгә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре һәм спорт
министрына

________________________________

______________________________дан
(Ф.И.Аи., биләгән вазыйфасы)

________________________________

Чит ил дәүләте, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый оешма
һәм дини берләшмәнең мактаулы яки махсус исемен,
бүләген алуга рөхсәт итүне сорау турында
үтенеч

Миңа ____________________________________________________________
(нинди күрсәткән хезмәтләр өчен һәм кем тарафыннан бирелә, күрсәткән нинди

______________________________________________________________________
хезмәтләр өчен һәм кем тарафыннан бүләкләнә)

______________________________________________________________________
(мактаулы яисә махсус исемгә, бүләккә документлар бирелүнең датасы һәм урыны)

______________________________________________________________________
(мактаулы яисә махсус исемнең, бүләкнең атамасы
алырга рөхсәт итүегезне сорыйм.

Мактаулы яисә махсус исемгә документлар, бүләк һәм аңа документлар,

(кирәклесе астына сызарга)

______________________________________________________________________

_________________________________________________________________

(мактаулы яисә махсус исемнең, бүләкнең атамасы)

______________________________________________________________________

(мактаулы яисә махсус исемгә, бүләккә документлар атамасы)

20__елның __ «_____» нан №__лы алыш-биреш акты буенча дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча секторга тапшырылды.

«___» __________ 20___ ел ______________ ________________________

(имза) (имзаны аныклау)

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре һәм спорт
министрлыгының
Татарстан Республикасы
дәүләт гражданлык
хезмәткәрләре тарафыннан
чит ил дәүләтләре, халыкара
оешмалар, сәяси партияләр,
башка иҗтимагый оешмалар
һәм дини берләшмәләрнең
мактаулы һәм махсус
исемнәрен, бүләкләрен алу
тәртибе турындагы
Нигезләмәгә
2нче кушымта

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре һәм спорт
министрына

___________________________________

_____________________________дан
(Ф.И.Аи., биләгән вазыйфасы)

___________________________________

Чит ил дәүләте, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый оешмалар һәм дини берләшмәнең мактаулы яки махсус исемен, бүләген алудан баш тарту турында белдерү кәгазе

___________________________________________________________________________

(мактаулы яисә махсус исемнең, бүләкнең атамасы)

___________________________________________________________________________.
(нинди күрсәткән хезмәтләр өчен һәм кем тарафыннан бирелә, нинди күрсәткән хезмәтләр өчен һәм кем тарафыннан бүләкләнә)

алудан баш тартуым турында карар кабул итүемне белдерәм.

«___» _____________ 20___ ел ___________ ___________________________
(имза) (имзаны аныклау)

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре һәм спорт
министрлыгының
Татарстан Республикасы
дәүләт гражданлык
хезмәткәрләре тарафыннан
чит ил дәүләтләре, халыкара
оешмалар, сәяси партияләр,
башка иҗтимагый оешмалар
һәм дини берләшмәләрнең
мактаулы һәм махсус
исемнәрен, бүләкләрен алу
тәртибе турындагы
Нигезләмәгә
3нче кушымта

Алыш-биреш акты

«_____»____________ 20___ ел

№_______

Без, түбәндә имза куючылар, әлеге актны түбәндәге хәл турында төзедек,

____________________________________________________________________________

(Ф.И.А.и., вазыйфасы) тапшырды/ кабул итеп алды (кирәклесе астына сызарга) Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт буенча министрлыгының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча секторының ____________________

_______________________ (вазыйфасы, Ф.И.А..и) ______________________________

түбәндәгеләрне тапшырды/ кабул итеп алды (кирәклесе астына сызарга):

| № | Атамасы | Саны (данә) | Тасвирламасы |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |

Тапшырды

___________ ( )
(имза) (имзаны аныклау)

Кабул итте

___________( )
(имза) (имзаны аныклау)

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының
Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан чит ил дәүләтләре, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый оешмалар һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен алу тәртибе турындагы Нигезләмәгә
4нче кушымта

Үтенеч (белдерү кәгазьләрен) исәпкә алу
ЖУРНАЛЫ

| № | Үтенеч (белдерү кәгазе) бирүче гражданлык хезмәткәренең Ф.И.А.и. | Үтенеч (белдерү кәгазе) бирүче гражданлык хезмәткәренең вазыйфасы | Үтенечнең (белдерү кәгазенең) керү көне | Бүләк, исем атамасы | Алыш-биреш актының реквизитлары (булган очракта) | Үтенечне (белдерү кәгазен) алучы затның имзасы, Ф.И.А.и. | Үтенеч (белдерү кәгазе) кабул итүче затның имзасы, Ф.И.А.и. | Министр карары турында мәгълүмат |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |